ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН БАШЛЫГЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«15» 06 2026 ел** **№ 148**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Балтач шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль план проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль район Башлыгы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Балтач шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль план проекты буенча Балтач шәһәр җирлеге халкы катнашында гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны оештыручы – коллегиаль киңәшмә органы составын расларга:

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе И.Д.Габдрахманов;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы И.Н.Сәгъдиев;

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе И. М. Фәтхетдинов;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты юридик бүлеге башлыгы Р.С.Фатыйхов;

- ГБУ "ИПП РТ" ("ТР Пространствоны планлаштыру институты") вәкиле.

3. Гавами тыңлауларны оештыручыга гавами тыңлауларны җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Гавами тыңлаулар уздыру вакытын, гавами тыңлаулар нәтиҗәсе белән кызыксынучы затларга аларны уздыру турында хәбәр итү вакытыннан башлап бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр, дип билгеләргә. Гавами тыңлаулар үткәрү срогы бер айдан артык була алмый.

5. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясында каралган гавами тыңлаулар башлануы турында хәбәрнамә әзерләргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач

муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль район
Башлыгы Р. Р. Нотфуллин